| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июнь № 446

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә кергән хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1170 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә кергән хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1170 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 февраль, 115 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка «Татарстан Республикасы» сүзләренә кадәр «гражданнарга һәм юридик затларга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә кергән хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибендә:

1.7 нче пунктта:

«дәүләт хезмәтләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан

Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТР ИСТҮ» ДБУ)» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 нче пунктта:

беренче абзацта «гамәлгә куючы... билгеләнә» сүзләреннән соң «, аларга карата тарифлар социаль хезмәтләрне җан башына финанслау нормативлары нигезендә билгеләнә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт социаль хезмәтләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «дәүләт хезмәтләре... билгеләнә» сүзләреннән соң «, аларга карата тарифлар социаль хезмәтләрне җан башына финанслау нормативлары нигезендә билгеләнә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт социаль хезмәтләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны төшереп калдырырга;

1.9 нчы пунктта:

өченче абзацта:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «ТР ИСТҮ» ДБУ» сүзләренә алмаштырырга;

«дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрдән тыш» сүзләрен «аларга карата тарифлар социаль хезмәтләрне җан башына финанслау нормативлары нигезендә билгеләнә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган, билгеләнгән дәүләт йөкләмәсенә өстәмә дәүләт социаль хезмәтләреннән тыш» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны төшереп калдырырга;

2.1 нче пунктның бишенче абзацында һәм 3.2 нче пунктның бишенче абзацында «финанс чыгымнары нормативы» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков